**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№8665**
**27.08.2026**

Яр Чаллы шәһәренең «Орион» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешнең 4 пункты, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы Карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы Карары белән расланган Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Орион» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.
2. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Орион» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2022 елның 22 декабрендәге 7460 номерлы Карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» вакытлы матбугат басмаларында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2026 елның 27 августындагы
8665 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең «Орион» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә
тарифлар

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәясе |
|---|---|---|---|
| I. Балаларның, яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең мәшгульлеген оештыру буенча хезмәтләр | | | |
| 1 | Киноклуб оештыру | кеше | 170,00 |
| II. Мәдәни-массакүләм, тамаша һәм спорт чаралары оештыру буенча хезмәтләр | | | |
| 2 | Театральләштерелгән һәм тематик бәйрәм программасы (көзге бал, Яңа ел, чыгарылыш кичәләре һ.б.) | кеше/сәгать | 700,00 |
| 3 | Конкурслар һәм фестивальләр үткәрү | кеше | 500,00 |
| 4 | «Дискотека» | кеше/сәгать | 150,00 |
| 5 | Тематик программа һәм күңел ачу уен программасы | кеше/сәгать | 450,00 |
| 6 | Иҗат мастерское | кеше/сәгать | 250,00 |
| 7 | Мастер – класс | кеше/сәгать | 450,00 |
| 8 | Күңел ачу уен программасы | кеше | 450,00 |
| 9 | Семинар (тренинг) оештыру һәм үткәрү | кеше/сәгать | 800,00 |
| III. Үстерү хезмәтләре | | | |
| 10 | «Әни белән бергәләп» программасы | 1 дәрес/1 кеше | 220,00 |
| 11 | «Стажерлар мәктәбе» программасы | 1 дәрес/1 кеше | 150,00 |
| IV. Өстәмә хезмәтләр | | | |
| 12 | Чараны утлар белән бизәү | 1 сәгать | 1 100,00 |
| 13 | Чараны утлар белән бизәү | 1 хезмәт/8 сәгать | 6 000,00 |
| 14 | Костюмнар прокаты | 1 тәүлек | 750,00 |
| 15 | Чарада тавыш операторы хезмәте | 1 сәгать | 600,00 |
| 16 | Тавыш яздыру өчен вокалчы хезмәте | 1 сәгать | 1 100,00 |
| 17 | Тавыш яздыру өчен диктор хезмәте | 1 сәгать | 1 100,00 |
| 18 | Тавыш юлын монтажлау (1 мин) | 1 хезмәт | 1 100,00 |
| 19 | Аранжировка ясау (әзерләү) | 1 хезмәт | 4 400,00 |
| 20 | Реклама аудио ролигы булдыру (җитештерү) (20 сек) | 1 хезмәт | 4 400,00 |
| 21 | Реклама аудио ролигы булдыру (җитештерү) (15 сек) | 1 хезмәт | 2 700,00 |
| 22 | Реклама аудио ролигы булдыру (җитештерү) (10 сек) | 1 хезмәт | 2 000,00 |
| 23 | Костюмлы персонаж хезмәте | 1 хезмәт | 1 500,00 |
| 24 | + форматында фонограмма яздыру хезмәте | 1 хезмәт | 2 000,00 |
| 25 | Чараның тавыш яңгырашы буенча тавыш режиссеры хезмәте | 1 хезмәт | 1 100,00 |
| 26 | Чараны видео ярдәмендә алып баруны оештыру | 1 хезмәт | 2 000,00 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 27 | Гардероб хезмәте күрсәтү | 1 чара | 270,00 |
| 28 | Чарада администратор хезмәте күрсәтү | 1 хезмәт | 550,00 |
| 29 | Чаралар үткәрү өчен алып баручы хезмәте | 1 хезмәт | 1 100,00 |
| 30 | Проектордан файдаланып, чараны видео ярдәмендә алып бару | 1 хезмәт | 1 100,00 |
| 31 | Конкурсларда һәм фестивальләрдә катнашу өчен оештыру взносы | кеше | 300,00 |
| 32 | Фото, видео- һәм аудиоязма хезмәтләре | сәгать | 1 300,00 |

«Орион» ЯҮ МАУ тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр:

- ата-аналары махсус хәрби операция зонасында булган балалар өчен, махсус хәрби операциядә катнашканда яралану сәбәпле дәваланудa булган граждан-хәрби хезмәткәрләрнең балалары өчен, махсус хәрби операциядә катнашу чорында алган хәрби травмалар яки авырулар нәтиҗәсендә 1 төркем инвалид булган граждан-хәрби хезмәткәрләрнең балалары өчен; ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен бушлай күрсәтелә;

- күп балалы гаиләләрдәге балалар өчен, сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикле балалар өчен, хәрби хәрәкәтләр ветераннарының балалары өчен 50 процент күләмендә ташлама белән күрсәтелә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева